

# *КАЛӘМ ТИБРӘТҮЧЕЛӘР*

**№ 3-4 2025 ел**

***98 нче татар – рус урта гомуми белем бирү мәктәбе***




**“Каләм тибрәтүчеләр” гәҗитен укучы кадерле дусларыбыз!**

Сезне **Яңа ел бәйрәме** белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Сезгә ныклы сәламәтлек, уңышлар, шатлык-куанычлар, гаилә бәхете, бәрәкәтле, мул тормышлар телибез!

Якынлашып килүче Ат елы- көч, тизлек, тугрылык, намуслылык, максатка омтылуны гәүдәләндерә. Ат һәрвакыт кеше янында булган: эштә дә, сәяхәттә дә, сугыш кырларында да. Аны фарфор вазаларда һәм тукымаларда сурәтләгәннәр. Ат сыны карьера үсешен, уңышны һәм алга китешне символлаштыра.

Ел уңыш китерсен өчен эчке күтәренкелек мөхим: искене җибәрегез, максатлар куегыз һәм ачык йөрәк белән киләчәккә барыгыз! Исән-сау, бәхетле булыгыз, һәр адымыгызда уңышлар юлдаш булсын!

Әй Яңа ел, бер  дә тартынмыйча,

Хуҗа булып, әйдә түргә уз!

Юлларыңа синең ак чәчәкләр,

Кулларыңа бездән ипи-тоз.

Менә сагынып көтеп алган Яңа ел бәйрәме дә килеп җитте. Һәркем бу бәйрәмдә ниндидер могҗиза, шатлык, куаныч көтә. Киләсе 2026 нчы ел-Ат елы. Атны инде без элек-электән иң тырыш, эшчән, сабыр хайван икәнен беләбез. Киләсе 2026 нчы елда һәрберебезгә тырышып эшләргә, эшебезнең уңай нәтиҗәсен күрергә, үз  алдыбызга куйган  максатларыбызга ирешергә язсын!

Татарстан республикасы рәисе Рөстәм Миннеханов 2026 нчы елны Халыклар бердәмлеге,  Хәрби һәм хезмәт батырлыгы елы дип  игълан итте. Бу тема Ватанны саклаучыларның батырлыгын һәм Татарстан халыкларының героик хезмәтен хөрмәт итәргә чакыра.

2026 нчы елда  Габдулла  Тукайның  тууына 140 ел була. Шул уңайдан Дөньякүләм татар конгрессы  2026 нчы елны Тукай елы дип игълан итте. Киләсе 2026 нчы елда, ягъни 26 нчы апрельдә  бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көне бөтен дөньяда  зур итеп бәйрәм ителәчәк.

Тукаема атап шигырь язам,

Бөеклеген аның күрсәтеп.

Күпме мирас  калдырган ул безгә

Татар халкына хезмәт итеп.

Шигырьләре белән рухланабыз,

Әкиятләр укып тәрбия алабыз.

Шагыйребез мирасын без бәялибез,

Киләчәккә аны тапшырабыз.

**югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Касыймова Гөлнур Наил кызы**

**Җәннәт-әниләрнең аяк астында**

**Әнием**

Әнием дип, кадерлем дип,
Кабатлыйм мин һәрвакыт.
Әни генә сине аңлый белә,
Күңел түрендәген кузгатып.

Эчке серләремне аңа сөйләп,
Күңелемдәген мин бушатам.
Киңәшләре белән ярдәм итә,
Кешелеклелеге белән юанам.

Әнием янында әтием бар,
Терәге ул аңа һәрвакыт.
Озак еллар тигезлектә яшәсеннәр,
Сәламәтлекләренә куанып.

**9А сыйныф укучысы Нәҗипова Әминә**

**“Бала чакта алган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас” Р.Фәхретдинов**




**Кешене нәрсә бәхетле итә ала?**

Минемчә, кешене иң беренче чиратта, эти-әнисе, Дәү эти, Дәү әнисе, якыннарының исән-сау һәм янәшәдә булуы бәхетле итә ала.

Иң кечкенә шатлык та кешене бәхетле итәргә мөмкин. Мәсәлән, иртә белән уянуга әни  пешергән тәмле коймак исләре, аның камыр ризыклары,  урамда яуган карга соклану, мәктәпкә бару, әйбәт билгеләр алу- болар барысы да кешене бәхетле итәргә мөмкин.

Бәхетле итүнең ысуллары күп. Шулай да, иң мөхиме-  эти-әниләребезнең безнең өчен  чын күңелдән  укылган  догалары безне чыннан да бәхетле итә ала. Шуңа күрә,  без эти-әниләребезнең сүзләрен тыңларга, аларга каршы әйтмәскә, һәрчак ярдәм кулы сузарга әзер торырга тиешбез. Һәрберебез бәхетле булыйк!

**6Б сыйныф укучысы Исхаков Ильяс**

## Яңа елга сынамышлар

Яңа ел кичендә яңа кием киегез - ел буе яңа киемнәрегез күп булыр. Елның беренче көне күңелле булса, ел буе шулай булачак. Яңа ел туганда кем дә булса төчкерсә, бөтен ел бәхетле булачак.
Яңа ел төнендә күк йөзе йолдызлы булса, уңышка.
Елның беренче көнендә авыр һәм кара эш башкарырга ярамый - ел буе бернинди ялсыз гел эшләргә туры киләчәк.

Тормышны чиста биттән башлагыз - кирәге калмаган әйберләрдән котылыгыз. Яңа ел өстәлендә азык һәм эчемлек күп булырга тиеш - бу киләсе елга байлык вәгъдә итә. Яңа ел кичендә әрләшергә, кычкырырга яки ямьсез сүзләр әйтергә ярамый - бу яңа елны "куркытырга" мөмкин һәм уңыш сездән һәм сезнең гаиләдән качарга мөмкин.

Яңа елда кер юарга һәм чүп чыгарырга ярамый - моның белән сез гаиләдән үзегезнең уңышыгызны чыгарасыз.
Беренче курантлар сукканнан соң беренче килгән кеше билгели - яңа ел сезнең гаиләгә нәрсә алып килә - әгәр сәламәт, бай кеше килсә, бу бәхеткә, әгәр беренче сез яратмый торган күршегез яки гел зарлана торган туганыгыз килсә, яхшы нәрсә көтмәгез. Элек шундый гадәт булган- яшьләр Яңа елны каршы алганнан соң, бөтен туганнарга һәм күршеләргә өйдән-өйгә йөреп уңыш китерергә ашыкканнар.

Ничек булса да, Яңа 2026 нчы ел барыбызга бары тик уңышлар, бәхет-шатлыклар алып килсен, дуслар!








**Редколлегия:**

**Касыймова Гөлнур Наил кызы**

**Әмирхан Еники, 23.**
**Тел: 8 (843) 236-24-12**

**Сездән язмалар көтеп калабыз!**